ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                    КАРАР

______________    с. Большие Меми    ______________

9

«Олы Меми авыл җирлеге территориясендә янгыннарны сүндерү көчләрен һәм чараларын җәлеп итү тәртибе турында»

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 21.12.1994 ел, №69-ФЗ Федераль закон, «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 30.12.2003 ел, №794 карары, «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасында янгыннарны сүндерүне оештыру һәм муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләрне, табигый бәла-казаларны кисәтүне һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү мәсьәләләрен хәл итүдә үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру турында килешүне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 15.10.2004 ел, № 559 карары белән, "Янгын куркынычсызлыгы турында» 2005 елдан 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, "Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасының территориаль подсистемасы турында " 10.11.2004 ел, №480 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә,Олы Меми авыл җирлеге территориясендә янгыннарны сүндерүне оештыру максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Янгын куркынычы килеп чыгу сәбәпле, учак ягу, җирлек территориясендә чүп-чарны яндыру һәм Олы Меми авыл җирлеге территориясендә урнашкан урманнарга автотранспортка керүне тыерга.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы көрәш куркынычсызлыгы буенча кизү торуны оештырырга.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгы буенча 05.04.2017 елдан 30.09.2017 елга кадәрге чорга оешма һәм предприятиеләр җитәкчеләренең кизү тору графигын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге территориясендә , җирлек характерындагы янгыннарны сүндерүне оештыру һәм гадәттән тыш хәлләрне, табигый бәла-казаларны булдырмау һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү мәсьәләләрен хәл итү өчен янгынга каршы куркынычсызлык буенча мобиль төркем булдырырга.

5. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегенең территориясендә янгынга каршы куркынычсызлык буенча мобиль төркем составын янгыннарны сүндерүне оештыру һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, табигый бәла-казаларны аларның нәтиҗәләрен бетерү мәсьәләләрен хәл итү өчен 2 нче кушымта нигезендә расларга.

6. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы куркынычсызлык буенча мобиль төркем составын җирлек характерындагы гадәттән тыш хәлләрне, табигый бәла-казаларны һәм янгын сүндерүне кисәтү өчен кирәкле инвентарь белән тәэмин итәргә.

3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге территориясендә янгыннарны, гадәттән тыш хәлләрне, табигый бәла-казаларны булдырмауга юнәлтелгән чаралар исемлеген расларга.

8. Янгын сүндерү гидрантларын, ранецларын сатып алуда, пирс белән Меминканы җиһазлауда Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты каршында үтенечнамә язарга.

9. Янгын булган очракта кешеләргә хәбәр итү өчен сигнализация чараларының төзеклеген тикшерергә, шулай ук авыл җирлегенең торак пунктларында янгын сүндерү өчен өстәмә савытлар урнаштырырга.

10. “Олы Меми авыл җирлегенең хәвеф-хәтәр зонасында урнашкан торак пунктлары җирләрен сукаларга

11. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

12. Карар аңа кул куйган вакыттан үз көченә керә.

.

Югары Ослан муниципаль районы

Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г.А. Фомина